ӘҢГӘМӘ
«Сәбәбен кылсак, Аллаһы Тәгалә юлын ачар»
→ 4 БИТ

СОРАУ-ҖАВАП
Хатын-кызларның саубуллашу тәвафы
→ 7 БИТ

САБЫЙГА
Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм
→ 9 БИТ

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ
Тәрбия яраладыр тәрбиядән
→ 12 БИТ

ФЕВРАЛЬ, 2023
№ 02 (331)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

РАҖӘБ-ШӘГЪБАН, 1444

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



Шәгъбан аенда өстенлекләргә ия булган бер кичә бар. Ул шәгъбан ае уртасының 14 еннән 15 нче кичәсенә каршы булган төн – Бәраәт кичәсе (быел ул 6 сыннан 7 нче мартка каршы төндә). Бәраәт кичәсе «гөнаһлардан арына торган көн» дип тәрҗемә ителә. Мөселманнар бу кичәне намазда, зикердә, догада үткәрә...

ДӘВАМЫ → 6 НЧЫ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (331) февраль, 2023 | раҗәб-шәгъбан, 1444

Татарстанда ачык телевизион «Вәгазь» бәйгесе башланды

Татарстанда ачык телевизион «Вәгазь» бәйгесе игълан ителде. Конкурс Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясе һәм ТР мөселманнары Дания нәзарәте тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән уздырыла. Төп максат – татар телендә оста вәгазьчеләрне ачыклау һәм халыкка таныту, үтемле итеп сөйләү үрнәкләрен күрсәтү.

Бәйгедә 15 яше тулган һәркем (нинди һөнәр иясе булуга карамастан) катнаша ала. Конкурсантлар яшь буенча аерым бәяләнәчәк:

а) 15 яшьтән 20 яшькә кадәр (15 һәм 20 яшьне дә кертеп) катнашучылар;

б) 21 яшьтән 35 яшькә кадәр (21 һәм 35 яшьне дә кертеп) катнашучылар;

в) 36 яшьлек һәм өлкәнрәк катнашучылар;

Конкурста катнашучыларга түбәндәге таләпләр куела: вәгазь татар телендә булырга, яттан сөйләнергә һәм 7 минуттан артмаска тиеш. Бәйге ике этапта уздырыла һәм йомгаклау тантанасы белән төгәлләнәчәк.

Конкурсның беренче этабы 2023 елның 15 нче февраленнән 1 нче октябрьгә кадәр (1 нче октябрьне дә кертеп) уздырыла. Беренче сайлап алу этабында катнашу өчен чыгышны видеоязма рәвешендә (телефонга төшерелсә дә ярый) tvvagaz@yandex.ru электрон почта адресына җибәрергә кирәк. Видеоязма белән бергә гаризаны да (катнашучының фамилиясе, исеме, шәһәре (районы), яше, вазифасы, башкарылачак вәгазьнең темасы) беркетү зарур.

Фото: dumrt.ru

Икенче этап барышында жюри (1 нче октябрьдән) конкурска килеп ирешкән эшләрне карый һәм тиешле категорияләр буенча ачык тавыш бирү юлы белән җиңүчеләрне билгели. Моннан тыш, конкурсның икенче этабында жюри йомгаклау тантанасында сөйләнәчәк вәгазьләрне сайлап ала.

Бәйгедә җиңүчеләр турында мәгълүмат Оештыручының рәсми сайтында, социаль челтәрләрдә урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басыла. Иң яхшы вәгазьләр атна саен Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясенең «Яңалыклар» чыгарылышында күрсәтеләчәк. Конкурсның йомгаклау тантанасы 2023 елның декабрь азагында үткәрелә. Бәйгедә җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылачак.

Бәйге турында тулырак мәгълүмат белән Нигезләмәдә танышып була.

(Игътибар! Нигезләмә һәм гариза язу мисалын ТР Дания нәзарәте сайтыннан алырга мөмкин – ред.).

dumrt.ru сайтыннан

Казанда Коръән укучылар бәйгесе узачак

2023 елның 11-12 нче мартында Казанның Мәрҗани мәчетендә хатын-кызлар арасында «Коръәнгә мәхәббәт белән» дип исемләнгән ачык Коръән бәйгесе узачак. Ул Казан Ислам университеты Коръән хафизлар әзерләү үзәгенең 20 еллыгына багышлап үткәрелә. Бәйгене Татарстан мөфтияте, Коръән хафизлар әзерләү үзәге, Мәрҗани мәчете һ.б. оештыра.

Конкурс 2 этапта үтәчәк: 11 нче мартта – сайлап алу туры, 12 нче мартта – төп тур. Сайлап алу турын үтү өчен катнашучыларга 11 нче март көнне иртәнге сәгать сигездә Мәрҗани мәчетенә килергә кирәк (адресы: Казан шәһәре, Каюм Насыйри урамы, 17 нче йорт). Бәйгедә катнашучыларга 4 номинация буенча белемнәрен күрсәтергә кирәк булачак:

- ✔ Коръәннең 30 нчы җөзен яттан белү
- ✔ 5 җөзне яттан белү («Әл-Әхкаф» – «Ән-Нәс»)
- ✔ 10 җөзне яттан белү («Әр-Рум» – «Ән-Нәс»)
- ✔ Тиләвәт (барлык тәҗвид кагыйдәләрен истә тотып, мосхафтан карап уку).

Бәйгедә, ничә яшьтә булуына карамастан, барлык хатын-кызлар катнаша ала.

Барлык номинацияләр өчен төп таләпләр: мәхраҗ һәм тәҗвидне белү, күрсәтелгән номинациягә туры килү, Коръәнне матур итеп уку. Һәрбер катнашучы бары бер генә номинациядә катнаша ала. Тулырак мәгълүмат конкурсның Нигезләмәсендә.

Бәйгедә җиңүчеләргә, беренче өч урын алучыларга кыйммәтле бүләкләр, шулай ук калган катнашучыларга да бүләкләр тапшырылачак.

Гаризалар 2023 елның 6 нчы мартына кадәр кабул ителә. Анкеталарны түбәндәге электрон адреска җибәрергә кирәк: **gulkamal1889@yandex.ru** (үрнәк бирелә).

Барлык сораулар белән мөрәҗәгать итү өчен телефоннар: **8 (908) 343-01-90, 8 (906) 115-36-01.**

(Игътибар! Бәйгенең Нигезләмәсен ТР Дания нәзарәте сайтыннан алырга мөмкин – ред.).

dumrt.ru сайтыннан

«Ибн Фадлан» фильмы киң прокатка чыга

«Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмы киң прокатка чыга – хәзер ул кинотеатр экраннарыннан күрсәтеләчәк. Аны 2023 елның 2 нче мартыннан башлап Казан, Түбән Кама, Уфа, Чаллы шәһәрләренең «Синема 5» кинотеатрлары челтәрләрендә барып карарга мөмкин:


Фото: dumrt.ru

- ✔ Казанда «Республика» сәүдә үзәге (Петербург ур., 9) һәм «Парк Хаус» сәүдә-күңәл ачу үзәге (Ямашев проспекты, 46/33);
- ✔ Уфада «Акварин» сәүдә-күңәл ачу үзәге (Ферин ур., 29);
- ✔ Түбән Камада «Синема 5» (Химиклар проспекты, 18, 2 нче корпус);
- ✔ Чаллыда «Синема 5» (Чулман проспекты, 89/57).

«Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмы – «Россия – ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме заказы буенча Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифе фонды ярдәме белән Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан төшерелде. Фильмның генераль продюсеры, документаль өлеш буенча режиссеры – Айназ Мөхәммәтҗанов, нәфис постановкалар буенча режиссеры – Рәмис Нәҗмиев.

Фильм Багдад илчелеге составында Идел буе Болгар дәүләтенә килгән гарәп дипломаты Әхмәд бине Фадланның юл язмаларына нигезләнгән. Илчелекнең килүе Идел Болгарстанында 922 елда Ислам дине рәсми дин буларак кабул ителү белән бәйле.

Картинада документаль һәм нәфис постановкалардан торган хикәяләү чиратлаштырыла. Документаль өлештә экспертларның әңгәмәләре һәм фикерләре китерелә. Фильмның консультантлары – Дәүләт эрмитажы директоры М.Б. Пиотровский, Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институты директоры А.К. Аликберов, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р.Р. Салихов, Россия Фәннәр академиясенең Матди мәдәният тарихы институтының өлкән фәнни хезмәткәре В.С. Кулешов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты Фаяз Хуҗин, Биләр тарих-археология һәм табигый музей-тыюлыгы директоры Зөфәр Шакиров һ.б.

«Ибн Фадлан»ның нәфис фильм өлешендә 921-922 елларның чынбарлыгын реконструкция рәвешендә тасвирлаган кадрлар һәм Ибне Фадлан, Алмыш хан һәм аларның даирәсендәге кешеләрнең рольләрен башкарган актерларның уеннары күрсәтелә. Массакүләм сәхнәләр һәм төрле эпизодлар өчен барлыгы 300 дән артык актер җәлеп ителде, 100 дән артык тарихи костюм тектерелде, 50 гә якын төрле реквизит әзерләнде. Алар арасында кылычлар, калканнар, сөңгеләр, хәрби киемнәр бар.

Кинотасма 2022 елда узган Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең ачышы булды һәм тамашачылар арасында зур кызыксыну уятты. Фестиваль вакытында фильм 4 тапкыр күрсәтелде һәм алар барысы да аншлаг белән узды.

dumrt.ru сайтыннан

Татар халкының күренекле шәхесләрен искә алдылар

15 нче февраль көнне Казанның Мәрҗани мәчетендә татар халкының олуг шәхесләренең рухларына багышлап Коръән уку мәҗлесе узды. Хөрмәтле затларыбыз Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Фатыйх Кәрим, Муса Җәлил, Илһам Шакировны олуглап, хәзрәтләр һәм абыстайлар Кәлам Шәрифтән аять вә сүрәләр укырга җыелды.

Фото: dumrt.ru

Коръән укып искә алу мәҗлесен Мәрҗани мәчетенең имам-хатыйбы, Казан шәһәренең Аксакаллар шурасы рәисе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов ачып җибәрде. Ул «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән мәкальне китереп, милләтнең горурлыгы булган шәхесләрне һәрвакыт дога кылып искә алу кирәклеген ассызыклады.

Алга таба Мәрҗани мәчете хәзрәтләре Коръәннән сүрәләр һәм аятьләр укыдылар, аннары Әнсар хәзрәт Мифтахов динебез, милләтебез өчен хезмәт куйган кардәшләребезнең исемнәрен атап дога кылды. Дин әһелләре, абыстайлар, остазбикәләр катнашында очрашу рухи-дини кыйммәтләрне саклау, үсеп килүче буынны Ислам дине кушканча тәрбияләү, белем бирү, дәгъват эшчәнлеге алып баруның актуаль мәсьәләләре хакында фикер алышу белән дәвам итте. Катнашучылар татар халкында Коръән ашлары үткәрү традициясе киң таралуын билгеләп, әлеге матур гадәтне дәвам итү, гомумән, мәҗлесләр үткәрү тәртипләре буенча теләк-тәкъдимнәрен җиткерделәр.

dumrt.ru сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (331) февраль, 2023 | раҗәб-шәгъбан, 1444

Исмәгыйль хәзрәт: «Сәбәбен кылсак, Аллаһы Тәгалә юлын ачар»

Хаҗ сәфәренә кузгалу бик изге һәм җаваплы гамәл. Әмма изге сәфәрдә бары үзең өчен генә җаваплы булу бер хәл, ә инде төркем җитәкчесе булу вазифасын өстеңә йөкләү аеруча да сабырлык, җитезлек һәм ихтыяр көче таләп итә. Ислам дине таралган җирләргә юл алучы кардәшләребез нинди әзерләккә ия булырга тиеш һәм нинди гамәлләрдән ерак булулары мөһим? Хаҗда кылган догаларның тиз арада кабул булу очраклары һәм башкалар хакында Теләче районы мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Фәләхиев белән әңгәмә кордык.

– Хәзрәт, әссәләмү галәйкүм! Кайчан беренче тапкыр җитәкче вазифасында әлеге җаваплы хезмәткә алындыгыз?

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Күп еллар дин юлында булсам да, беренче тапкыр олы хаҗга 2017 елда гына бара алдым. Шушы сәфәрдән соң миңа төркем җитәкчесе булып бару тәкъдиме ясалды. Һәм 2018 елда кардәшләребезнең җитәкчесе буларак юлга кузгалдым. Бу эшкә алынуның максаты – хаҗи-хаҗияләребез гамәлләрен төгәл һәм дөрес үтәеннәр дигән ният булуда иде, чөнки кайвакытта кешенең шушы гамәлләрне өйрәнеп бетмәве, белмәве аның өчен авырлыклар китереп чыгарганын күзәтәбез.

– Хаҗга барырга ниятләүче кешегә, юлга кузгалганчы ук, нәрсәләрне катгый рәвештә белеп тору зарур?

– Әлбәттә, хаҗга барырга теләгән кешедә иң беренче чиратта зур сәфәргә чыгар өчен ният булырга тиеш. Аннары чит ил паспортын эшләтеп кую мөһим. Изге сәфәргә җыенучы кеше, хаҗы камил рәвештә башкарылсын өчен, аның гамәлләрен, тәртибен яхшылап өйрәнергә бурычлы. Кеше боларга җиңел карап: «Баргач, шунда өйрәнеп бетерермен әле», – дип фикер йөртергә тиеш түгел, аның күңелендә хаҗ сәфәрен булдыра алганча дөрес рәвештә кылып, Раббымның әҗер-савабына ирешәм дигән ныклы ният булу мөһим.

Шулай ук, хаҗга барырга ниятләгән кеше үзенең матди ягын кайгырта башларга тиеш. Әгәр игътибар итсәк, кеше дөнья максатына ирешер өчен, ягъни ни дә булса сатып алырга яки каядыр барырга теләсә, аерым бер касса булдыра, үз-үзенә: «Бу акчага тимим, максатыма ирешер өчен, аны җыям», – дип сүз бирә. Һәм, ниһаять, куйган максатына да ирешә. Раббыбыз безгә хаҗ кылу гамәлен гомер эчендә бер тапкыр кылуны гына фарыз итеп билгеләгән. Шуңа да әгәр кеше үзенә изге сәфәргә чыгу максатын куя икән, Раббыбыз аңа бу юлда Үзе ярдәм итә: ул кешенең матди ягы да хәл ителә, башка мөмкинлекләре дә чыга.

– Хаҗда иң еш күзәтелә торган, иң күп таралган хата нинди?

– Чыннан да, кеше хаҗда хаталар да җибәрергә мөмкин. Кеше күп булган җирдә кемнедер тикшереп, гайбәткә дә кереп китүе бар. Шуңа да ул хаҗга ни өчен килгәнен исендә тотарга: «Мин хаҗда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөргән җирләрендә», – дип уйларга, хаҗиларны, шушы җирлектә яшәүче кешеләрне тикшерергә түгел, ә һәркем кылган гамәле өчен бары үзе генә җавап тотачагын хәтереннән чыгармаска тиеш. Хаталарга килгәндә, кеше никадәр генә сабыр булса да, кайчакларда җитәкчеләргә итагать итмәү очраклары да булгалый. Мәсәлән, «сабыр итәргә, көтәргә» дип әйтелсә, алар ашыгырга яисә «шул вакытта җыелабыз» диелсә, соңга калырга мөмкин. Монда да сабырлык һәм билгеләнгән җитәкчеләрне хөрмәт итү сорала.

– Хаҗ вакытында нәрсә иң күп сабырлык, көч таләп итә?

– Гомумән, хаҗ сәфәре дә, аның гамәлләре дә сабырлык таләп итә. Хаҗда бары бер урында гына сабырлык кирәк, дип әйтеп булмый, хаҗда бөтен җирдә дә сабыр булу тиешле. Мәсәлән, кеше күп булгач, кайбер урыннарга кереп булмаска мөмкин, тәртип саклаучыларның анда керергә рөхсәт итмәүләре бар. Шул сәбәпле, еш кына кешенең: «Ник кертмиләр инде, ерак җирләрдән килдек бит», –

Фото авторның шәхси архивыннан

дип күңеле төшә. Менә монда да сабырлык күрсәтеп, бу хәлне хәерлесе дип кабул итү мөһим.

Сабыр булуның кирәклеге, мөһимлеге талчыкканда, хәлсезләнгәндә бигрәк тә сизелә. Кешенең вакыты чикле, ә гамәл-гыйбадәтне күбрәк кыласы килә, кеше күп көч сарыф итеп арый, ә арыган кеше сабырсызлана башлый. Шуңа да сәфәргә җыенучы кеше боларга игътибарлы булырга тиеш.

– Сәфәрдәшләрегез изге җирләрдә кылган догаларының тиз арада кабул булуы хакында ниләр сөйли?

– Әлбәттә, Кәгъбәтуллаһ янында кылынган догаларның кабуллыгында шик юк. Аның мисаллары да шактый. Кардәшләребез олы хаҗда түгел, ә кече хаҗ – гомрәдә кылынган догаларның кабул булуы хакында да шаккатып сөйли. Мәсәлән, йөкле хатын-кызларның: «Хаҗ сәфәрендә кылган догалар кабул булды. Аллаһының рәхмәте белән, баламны җиңеллек белән, тиз таптым», – дип шыл-тыратып сөйләгән очраклары бар. Шундый хәл дә булды, бер ана кеше: «Улым тәртипсезрәк юлда йөри, кайтып күренгәне юк, инде биш ел аннан бер хәбәр дә алмыйча яшим, кайда икәнен дә белмим. Хәере белән, исәнсау кайтса иде, дип дога кылыгыз әле», – дип мөрәҗәгать иткән иде. Дога кылучы кешеләр хәтта гомрәдән кайтып җиткәнче үк, әлеге хатын-кыз улының өйгә кайтуы хакында хәбәр бирде. Әлбәттә, бу ихластан кылынган доганың нәтиҗәсе бит. Дога кылу – ул бик көчле гамәл. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәл-

ләм юкка гына: «Дога – мөселманның коралы», – дип әйтмәгән. Ихластан кылынган дога нәтиҗәсез калмый.

– Изге җирләрдә бергә йөргән кардәшләрегез белән туган якларга кайткач та элемтә сакланамы?

– Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кардәшеңне белер өчен, аның белән өч халәттә булып кара: сәфәрдә бул, бурычка акча бир һәм бергәләп эш эшләп карагыз. Шуннан соң кардәшеңнең кемлеге ачыкланыр», – дигән.

Изге җирләргә бергә барган хаҗи-хаҗияләр туганнар кебек якын була, алар белән туган якларга кайтканнан соң да элемтә бар, һәрберсе белән язышып, күрешеп торабыз.

– «Хаҗга барыр идем дә, әмма мөмкинлегем юк: акчам җитми, саулыгым начар» дип әйтүчеләргә нинди киңәш, үгет-нәсыйхәтләр бирер идегез?

– Әлбәттә, иң беренче чиратта кешедә Аллаһының фарызын үтим, дигән ныклы ният булырга тиеш. Аллаһыдан: «Йә, Раббым, изге сәфәрләргә баруны насыйп итсәң иде», – дип сорарга кирәк. Беркайчан да өметсез булырга ярамый, чөнки Раббыбыз Коръәндә: «Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез», – дип әйтә («Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53). Хәтта сәламәтлегебез юк, дип әйтсәк тә, хаҗда тәваф кылган вакытта аягы булмаган, күзе күрмәгән хаҗи-хаҗияләрне күреп, үзебезне сәламәт түгел дип санавыбыз өчен оялабыз, саулыгыбызның, аларныкы белән чагыштырганда, күпкә яхшырак икәненә инанабыз. Шуңа да сәбәп табып, Раббыбыз фарыз кылган гамәлләргә «кылып булмый» дип нәтиҗә чыгарып куярга ярамый. Сәбәбен кылсак, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгалә юлын да ачар, мөмкинлеген дә бирер, сәламәтлегебезне дә ныгытыр.

Хаҗга барган һәр кеше сәфәр вакытында гаҗәпләнеп: «Әгәр гади вакытта мин бу кадәр йөрсәм, аякларым шешенер иде, болай озак йөри алмас идем», – дип әйтә. Хаҗда, чыннан да, Аллаһының хикмәтен, бәрәкәтен күрәбез. Кеше тәваф кылганнан соң, яшәгән урынына кайтып, бераз ял итеп алса, талчыгуның әсәре дә калмый, икенче көнне яңадан гамәл-гыйбадәтләрен кылырга чыгып китә. Шуңа да изге җирләрдә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәмен бирүен аңларга кирәк.

Әңгәмәне **Айсылу Юлдашева** оештырды

ИСТИХАРӘ НАМАЗЫ

Фото: shutterstock.com

Истихарә намазы – нинди дидер олуг эшне башлар алдыннан, шуның хәерле булуын теләп укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы.

Истихарә намазыннан соң әлеге дога укыла:

اَللَّهُمَّ إِنِّى اَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ وَاسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ وَأَسْئَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِمِ فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلَا أَقْدِرُ وَتَعْلَمُ وَلَا أَعْلَمُ وَأَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ اَللَّهُمَّ إِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الْأَمْرَ خَيْرٌ لِى فِى دِينِى وَمَعَاشِى وَعَاقِبَةِ أَمْرِى فَاقْدِرْهُ لِى وَيَسِّرْهُ لِى ثُمَّ بَارِكْ لِى فِيهِ وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الْأَمْرَ شَرٌّ لِى فِى دِينِى وَمَعَاشِى وَعَاقِبَةِ أَمْرِى فَاصْرِفْهُ عَلَى وَاصْرِفْنِى عَنْهُ وَاقْدِرْ لِى الْخَيْرَ أَيْنَمَا كُنْتُ إِنَّكَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ

Аллаһүммә иннии әстәхыйрүкә бигыйльмикә вә әстәкъдирүкә бикудратикә вә әс-әлүкә мин фәдъликәл-гаҙыйми фәиннәкә тәкъдиру вә ләә әкъдиру вә тәгъләмү вә ләә әгъләмү вә әнтә галләәмүл-гуйүүб. Аллаһүммә ин күнтә тәгъләмү әннә һәәҙәәл-әмра хайрун лии фии диинии вә мәгаашии вә гаакыйбәти әмрии фәкъдирһү лии вә йәссирһү лии çүммә бәәрик лии фииһ. Вә ин күнтә тәгъләмү әннә һәәҙәәл-әмра шәррун лии фии диинии вә мәгаашии вә гаакыйбәти әмрии фәсрифһү галәә вәсрифнии ганһү вәкъдир лил-хайра әйнәмәә күнтү. Иннәкә галәә күлли шәй-ин кадиир.

Мәгънәсе: «Йә, Раббым, дөреслектә, мин Синнән Үз гыйлемең белән ярдәм итүеңне, кодрәтең белән миңа көч бирүеңне һәм Синең олуг рәхмәтеңне сорыйм. Дөреслектә, Синең кодрәтең бар нәрсәгә җитә, мин үзем генә (Синең кодрәтең булмаса) һичбер нәрсә эшли алмыйм. Син һәрнәрсәне беләсең, ә мин белмим. Дөреслектә, Син һәрбер яшерен нәрсәләрне беләсең. Йә, Аллаһы, әгәр бу эшемне динем, дөньям һәм Ахирәтем өчен хәерле дип белсәң, аны миңа насыйп ит һәм ул эшне минем өчен мөбарәк кыл. Әгәр дә бу эшемне динем, дөньям һәм Ахирәтем өчен зарарлы һәм яман дип белсәң, ул эшне миннән һәм мине ул эштән азат ит. Кайда булсам да, миңа хәерле эшләрне насыйп ит. Дөреслектә, Синең көчеңә һәрнәрсәгә җитә».

Моны укыганнан соң кешенең әлеге эшкә күңеле тартса, хәерле булуына өмет итеп, аны башлар. Әгәр дә аның күңеле тартылмаса, үз ихтыярында калыр. Ниндидер бер хәерле эшне башлаган вакытта да, рәсми мәҗлесләрдә дә шушы доганы укырга мөмкин.

«365 көн догада» китабыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (331) февраль, 2023 | раҗәб-шәгъбан, 1444

БӘРАӘТ КИЧӘСЕ – ДОГАДА БУЛУ ВАКЫТЫ

Мөхтәрәм җәмәгать, Рамазан ае да якынлашып килә. Шәгъбән ае Рамазанга әзерләнә торган ай ул. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң күп уразаны шәгъбән аенда тоткан дип риваять ителә. Хәдистә килгәнчә, Үсәмә бине Зәед радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезгә: «Әй Аллаһының Расүле! Шәгъбан аеннан кала, башка айларда синең шул кадәр ураза тотканыңны күргәнем булмады», – дип әйткән. Пәйгамбәребез аңа: «Раҗәб белән Рамазан айлары арасында булган бу ай хакында кешеләр гафил. Бу айда кылган гамәлләр Галәмнәрнең Раббысы хозурына күтәреләдер. Шуңа да гамәлләрем күтәрелгән вакытта уразада булуымны телим», – дип җавап биргән (имам Ән-Нәсаи).

ГӨНАҺЛАРДАН АРЫНА ТОРГАН КӨН

Шәгъбан аенда өстенлекләргә ия булган бер кичә бар. Ул шәгъбан ае уртасының 14 еннән 15 нче кичәсенә каршы булган төн – Бәраәт кичәсе (быел ул 6 сыннан 7 нче мартка каршы төндә). Бәраәт кичәсе «гөнаһлардан арына торган көн» дип тәрҗемә ителә. Мөселманнар бу кичәне, өстенлекләргә ия булу өчен, намазда, зикердә, догада үткәрә. Кызганычка, безнең җирлектә яшәүче күпчелек мөселманнар бу кичәне белми һәм аны билгеләп үтү дөрес буламы икән дип, шикләнеп тә карый. Шикләнәсе юк, бу кичәнең өстенлеге хакында хәдисләр бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Гыйззә вә Җәллә шәгъбан ае уртасының төнендә колларына карый, мөшриктән һәм кардәшенә ачу саклаучыдан кала, барлык колларын да ярлыкый», – дигән (имам Әт-Табәрани).

Киләсе хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шәгъбан ае уртасының төнендә Аллаһы Үзенең колларына карар, мәәминнәрне ярлыкар, имансызларны ярлыкарга ашыкмас, ә инде ачу саклаучыны, моннан арынганчы, ачуы белән калдырыр», – дип әйткән (имам Әл-Бәйһакый).

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Шәгъбан ае уртасының төнендә Аллаһының Рәхмәте дөнья күгенә төшәр һәм, Бәнү Кәлб кабиләсе сарыкларының йон бөртекләре кадәр, колларының гөнаһларын ярлыкар» (имамнар Әхмәд, Әт-Табәрани).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыны Гайшә радыяллаһу ганһәдән: «Бу төннең нинди төн икәнен беләсеңме?» – дип сораган. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Бу хакта Аллаһы һәм Аның Расүле генә белә», – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез: «Бу шәгъбан ае уртасының төне. Аллаһы Гыйззә вә Җәллә бу төндә колларына карар һәм ярлыкау сораучыларны ярлыкар, Рәхмәтен сораучыларга Рәхмәтен ирештерер. Әмма ачу саклап йөрүчеләрне үз хәлләрендә калдырыр», – дип әйткән (имам Әл-Бәйһакый).

БУ КИЧӘНЕ НИЧЕК ҮТКӘРЕРГӘ?

Әлеге һәм бу хактагы башка хәдисләргә нигезләнеп, күпчелек галимнәр шәгъбан аеның 15 нче кичәсен гыйбадәттә, зикердә, истигъфарда, догада үткәрүне хуп күрде. Моның өчен хәтта төнлә белән уяну да кирәк түгел. Әгәр без ятар алдыннан күпмедер вакытыбызны гыйбадәттә, намазда уздырсак, бу төнне гафләттә үткәргән булмабыз һәм, иншәАллаһ, Пәйгамбәребез әйткән әҗерләргә, өстенлекләргә ирешербез.

БӘРАӘТ КИЧӘСЕНЕҢ ӘХЛАКЫЙ ДӘРЕСЛӘРЕ

Әйтелгән бу хәдисләргә карасак, алардан үзебезгә әхлакый дәресләр дә алабыз. Беренчесе, биредә үз кардәшләренә ачу саклап, алардан аерылып йөрүчеләр хакында искә алына. Хәдистә ул кеше «мушахин» дип әйтелә. Андыйлар күңелләрендә булган ачуны юк итеп, үз кардәшләре белән килешми торып, бу кичтә дә һәм, гомумән, башка вакытта да ярлыканмас, Аллаһының Рәхмәтенә дә ия була алмас. Әмма күңелдәге ачуны бетереп, кардәшең белән килешү өчен, аңа кул сузу зур көч сорый торган эштер. Кардәше белән килешүче – көчле мөәминдер. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселман кешеләре үзенең кардәшенә ачуланып, өч көннән дә артыграк вакытка аннан читләшергә, бер-берләреннән йөзләрен борырга тиеш түгел. Аларның иң хәерлесе – беренче булып сәлам бирүче», – дип әйткән (имамнар Мөслим, Әл-Бохари).

Хәдистән аңлашылганча, ачуланып, бер-береңнән читләшеп, күрешмичә йөрү зур гөнаһтыр. Ә бертуганыңнан читләшүнең гөнаһысы икеләтә булыр. Менә мондый читләшүләр мөселманнарны тарката, зәгыйфьләндерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселманнар бер-берсен ныгыта торган таш бина кебек нык булырга тиешләр», – дигән. Икенчедән, Пәйгамбәребез бу кичәдә уяу булучыга Аллаһы Рәхимле булып, аның гөнаһларын ярлыкар, дип әйтә. Бәраәт кичәсе – гөнаһлардан арына торган кичәдер. Кеше күпме генә гөнаһ кылмасын, аның гөнаһлары биек таулар кебек күп булса да, Аллаһының Рәхмәте һәм ярлыкавы тагы да зуррак. Пәйгамбәребез безгә Аллаһының тәүбә капкалары хакында сөйләгәндә үзенең сахих хәдисләрендә: «Кеше бу капкаларның бер кырыеннан икенче кырыена кадәр атка атланып, җитмеш ел чабар иде», – дип әйткән. Хәтта бөтен дөнья халкы: кешеләр һәм җеннәр барысы бергә берьюлы тәүбә-истигъфар кылсалар да, бу капкалар аларның тәүбәләрен сыйдырыр иде. Кеше истигъфардан туктаганчы, хәтта аның җаны бугазына җиткәнче, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә аның гөнаһларын ярлыкавын дәвам итәчәк.

Марат Сәйфетдинов,
Балтач Үзәк мәчетенең икенче имам-хатыйбы, мөгаллим

Сөннәт намазларын каза кылу турында Нәзарәт фәтвасы

СОРАУ: Әссәләмү галәйкүм! Җөнеб хәлендә булганнан соң, онытылып китеп, госел коенасы урынга тәһарәт алганмын. Миңа хәзер сөннәт һәм фарыз намазларын яңадан укыргa кирәкме, әллә фарыз намазларын гынамы?

ҖАВАП:

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы исеме белән. Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Тәһарәтле һәм госелле булу намазның дөреслеге өчен шарт булып тора. Аллаһы бу хакта Коръәндә:

***«Әгәр** [намаз укырга кирәк булганда] **җөнеб булсагыз,** [госел коенып] **пакьләнегез»,** – дип әйтә.*

«Әл-Маидә / Табын», 5:6

Сезнең очракта фарыз, витр намазларын һәм иртәнге намазның сөннәтен үтәргә кирәк (әгәр сез госел коенмаган килеш иртәнге намазны укыган булсагыз).

«Бәдаигъ әс-санаигъ» китабында болай дип әйтелә:

«Ә инде сөннәт [сөннәт намазы] мәсьәләсен аңлатуга килгәндә, сөннәт намазы укылмый калган булса, аны каза кылырга кирәк буламы? Без ярдәмнең бары Аллаһыдан булуын гына әйтә алабыз: безнең фикердәшләребездә бу мәсьәләдә, иртәнге намазның сөннәтен каза кылудан кала, каршылыклар юк. Әгәр алар [сөннәт намазлары] укылмый калган икән – каза кылынмый, һәм монда фарыз намазы белән бергә яки аннан башкамы [укылмый калган] – аерма юк» («Бәдаигъ әс-санаигъ фи тәртиб әш-шәраигъ», Галәведдин әл-Касани. 1/287).

Шулай ук:

«Ә иртәнге намазның сөннәтенә килгәндә, әгәр аның белән бергә фарыз намазы да укылмаган булса, сөннәтне каза кылырга кирәк. Бу хакта «төнге үткел» («ночной перевал») турында хәдистә әйтелә» («Бәдаигъ әс-санаигъ фи тәртиб әш-шәраигъ», Галәведдин әл-Касани. 1/287).

Һәм Аллаһы яхшырак Белүче.

Хатын-кызларның саубуллашу тәвафы турында

СОРАУ: Әссәләмү галәйкүм! Әгәр хаҗ вакытында саубуллашу тәвафы буласы көнне хатын-кызның күреме башланса, нишләргә? Саубуллашу тәвафын кылу мәҗбүри бит.

ҖАВАП:

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы исеме белән. Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Хәнәфи мәзһәбе буенча, саубуллашу тәвафын кылу мәҗбүри. Әгәр хатын-кызның күреме башланган һәм ул Мәккәдән киткәнче бу тәвафны кылып өлгерә алмый икән, аның өстеннән саубуллашу тәвафын кылу бурычы төшә.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешеләргә Мәккәдән киткәнче соңгы үтәгән йола итеп Аллаһы йорты тирәли әйләнеп чыгарга боерылды, һәм бу мәсьәлә күрем күргән хатын-кызларга гына җиңеләйтелә», – дигән.

Кара. «Сахих Әл-Бохари», №1755.

«Һәм бездә бу мәсьәләдә [саубуллашу тәвафын кылу мәҗбүрилегенә дәлил булып] Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Хаҗ кылган кешенең соңгы йоласы Аллаһы йорты тирәли әйләнеп чыгу булсын, һәм хатын-кызларга гына күремнәре вакытында җиңеллек бирелә», – дигән сүзләре тора.

«Аның үтәгән соңгы йоласы булсын» – فَلْيَكُنْ آخِرُ عَهْدِهِمْ дигән боеру бу гамәлнең мәҗбүрилеген күрсәтә, һәм хатын-кызларга күрем вакытында саубуллашу тәвафын кылмаска рөхсәт бирелү шулай ук аларга тәвафны үтәмичә калдыруның мәҗбүрилеген күрсәтә».

Кара: «Әл-Мәбсут», Әс-Сарахси, 4/35.

Аллаһы яхшырак Белүче.

Намазда тәшәһһүд урынына «Әл-Фатиха» сүрәсен уку

СОРАУ: Намаз вакытында, онытылып китеп, тәшәһһүд урынына «Әл-Фатиха» сүрәсен укысаң, ни була?

ҖАВАП:

Ялгышып тәшәһһүд урынына «Әл-Фатиха» сүрәсен укыгансыз икән, сезгә намаз ахырында сәһү сәҗдәсе кылырга кирәк, чөнки сез хаталанып вәҗибне («тәшәһһүд» укуны) кичектергәнсез.

ДӘЛИЛ: Сәүбән радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Расүлуллаһ: «Һәр хата аркасында, сәлам биргәннән соң, ике тапкыр сәҗдә кылу тиеш», – дигән.

Кара: «Сөнән Әбү Давыд», №1038.

«Вәҗибне калдыру яки кичектерү очрагында гына, [сәһү сәҗдәсе кылу] мәҗбүри.

Кара: «Әл-Һидәя фи шәрх Бидая Әл-Мүбтади», 1/74.

Аллаһы яхшырак Белүче.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең фәтвалар бүлеге (даруль-ифта)

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (331) февраль, 2023 | раҗәб-шәгъбан, 1444

КАЗАНДА ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДИ ФОРУМ УЗАЧАК

14 февраль көнне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында «Россия – ислам дөньясы: Kazanforum» халыкара икътисади форумын оештыруга һәм үткәрүгә багышланган брифинг узды. 2023 елгы форумны уздыру үзенчәлекләре турында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Газинур Бакиров, Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе генераль директоры Максим Денисов сөйләде.

Фото: dumrt.ru

Талия ханым Миңнуллина, Россия Федерациясе һәм Ислам дөньясы илләренең икътисади хезмәттәшлегенең төп мәйданчыгына әверелгән форумның аерым чараларына күзәтү ясап, быел Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең Халыкара икътисадый форумы 18-19 май көннәрендә Казанда «Россия – ислам дөньясы: Kazanforum» исеме астында Халыкара күргәзмәләр үзәгендә узачак, дип билгеләп үтте. Форумны әзерләү һәм уздыру буенча федераль оештыру комитетын Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин җитәкли.

Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе сүзләренчә, быел форумны оештыруда зур үзгәрешләр булды: хәзер ул федераль статуска ия. Форумда «Халыкара хезмәттәшлек», «Ислам финансылары», «Хәләл индустриясе», «Бизнес мөмкинлекләре», «Технологияләр», «Стартап кластер», «Инвестицияләр», «Логистика», «Тотрыклы үсеш максатлары зонасы», «Хатын-кыз карашы» һ.б. блокларны үз эченә алган 200гә якын чара һәм 127 эшлекле сессия көтелә.

Моннан тыш, форум программасына гадәттәгечә хәләл индустриясенең ел саен уза торган RUSSIA HALAL EXPO халыкара күргәзмә экспозициясе һәм «Изге Болгар җыены» кертелде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышын җир тетрәүләр вакытында зыян күргән һәм авырлыклар кичергән Сүрия һәм Төркия халыкларының кайгысын уртаклашудан башлады.

Бүгенге очрашу темасы буенча ул саммитның федераль дәрәҗәгә чыгуы илнең югары җитәкчелегенең Ислам дөньясы белән мөнәсәбәтләрне һәм Россия эчендә Halal lifestyle концепциясен үстерүгә әзерлеген дәлилли, дип билгеләп үтте. Шул ук вакытта ул элегрәк һәр саммитның чит илләрдәге хәләл индустриясендә катнашучыларның Татарстанга һәм Россиягә карата зур кызыксыну күрсәтүен ассызыклады.

Нигездә, аларның игътибарын Татарстанның хәләл-сертификацияләү һәм Ислам финансларын үстерү өлкәсендәге тәҗрибәсе җәлеп итә иде. Мисал итеп ул Бразилиянең Fambras Halal компаниясен китерде – алар хәләл продуктларны сертификацияләү буенча дөньядагы иң зур орган булып тора:

– Барлык гарәп дәүләтләре дә диярлек хәләл продукцияне үз илләренә кертү өчен әлеге компания белән хезмәттәшлек итә, – дип билгеләп үтте мөфти. – Бу сәер яңгыраса да, моның сәбәбе бик гади: Бразилиянең һава торышы терлек асрау өчен бик уңайлы. Шуңа күрә хәтта хаҗ вакытында да Согуд Гарәбстанына бу компания тарафыннан сертификацияләнгән җитештерүчеләр үстергән ит китерелә. Без дә хәзер алар белән килешүләр төзедек, алар безне дөньяның хәләл базарына чыгу өчен нәрсә һәм ничек эшләргә кирәклеген күрсәтәчәк. Бразилиядә бу мөмкин булгач, әллә Россиядә мөмкин түгелме?

Камил хәзрәт Сәмигуллин шулай ук соңгы 2 елда Татарстанның Ислам финансылары өлкәсендә дә сизелерлек алга китүе хакында хәбәр итте. Шул исәптән Форумның мәйданчыклары һәм элемтәләре ярдәмендә дә.

Әйтик, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы 5 хәләл продукт эшләде, алар арасында «Ак барс Банк»та күчемсез милек сатып алу өчен хәләл рассрочка һәм банк картасы һ.б. Моннан тыш, РИИ каршындагы Техник комитет белгечләре тарафыннан бүгенге көндә 9 бердәм федераль хәләл стандарт эшләнде, шуларның дүртесе Росстандартта кабул ителгән, бишесен кабул итәргә әзерләнәләр.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чыгышында шулай ук быелгы «Изге Болгар җыены»ның иң мөһим серен ачты: оештыручылар хәзер Болгарга килүчеләр өчен беренче тапкыр пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җир шарының төрле почмакларында саклана торган 11 мөкатдәс әманәтен алып килү мөмкинлеген карый.

dumrt.ru сайтыннан

Кадерле дустым, газетабызның алдагы саннарында сине Коръәни Кәримебездә искә алынган пәйгамбәрләребезнең кыйссалары белән таныштырып килгән идек. Язганнарыбыз сиңа файдалы һәм кызыклы булгандыр, син аннан үзеңә күп үгет-нәсыйхәтләр алгансыңдыр дип ышанабыз. Алга таба язмаларыбыз Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланачак. Расүлуллаһның тормыш юлы, нәсыйхәтләре, күркәм холкы синең өчен үрнәк булса иде, дигән изге теләктә калабыз.

МӨХӘММӘД САЛЛӘЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ВӘ СӘЛЛӘМ

Аны барысы да көтте

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кадәр булган чор «җәһилият» дип аталган. Бу наданлык, адашканлык вакыты. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм килгәнче кешеләр дөрес яшәмәгән, үз куллары белән ясаган төрле потларга табынган, хаксызга көчсезләрне рәнҗеткән, туганнар белән араны боза торган булган, хәтта гаиләдә кыз бала туса, моны хурлыкка санаган. Бай кешеләр өйләрендә коллар тотып, аларны кыерсыткан, Кәгъбәтуллаһ потлар белән тулы булган.

Җәмгыятьтә бу хәлләргә ризасызлык белдергән кешеләр булса да, алар бу гаделсезлекләргә каршы чыга алмаган, чөнки үзләре генә нәрсәне дә булса үзгәртә алмауларын аңлаганнар. Әмма алар Аллаһы Тәгаләнең җир йөзенә туры юлны күрсәтүче кеше җибәрәчәгенә ихластан ышанган, чөнки элеккеге заманнарда да дөрес яшәмәгән халыкларга пәйгамбәр килә торган булган. Бу пәйгамбәрләр халыкны караңгылыктан нурга алып чыгар өчен күп тырышлык куйган, араларында кайберләре пәйгамбәрләр әйткәннәргә иман китереп, һидаять юлын сайлаган, ә калганнары тәкәбберләнеп, пәйгамбәрләрне кире каккан. Менә шундый җаваплы һәм авыр вазифа йөкләнгән барлык пәйгамбәрләргә дә.

Пәйгамбәрләрнең үз халыкларын бер илаһлыкка чакыруда очрашкан авырлыклары, күргән гаделсезлекләре хакында газетабызның алдагы саннарында бәян иткән идек.

Әйткәнебезчә, алга таба сабыйга сәхифәбез Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланачак.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында Коръәни Кәримдә болай диелгән:

*«[Расүлем!] **Без сине** [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] **бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».***

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм соңгы пәйгамбәр һәм ул

Фото: shutterstock.com

аерым бер халык өчен генә түгел, ә бөтен галәмнәр өчен җибәрелгән. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик күркәм холыклы, миһербанлы, шәфкатьле, гадел кеше булган. ИншәАллаһ, киләсе саннарда болар хакында тулырак язарбыз.

Сәхифәне **Айсылу Юлдашева** әзерләде

ХАҖ 2023

Хаҗга барырга теләүчеләр түбәндәге номерлар буенча элемтәгә керә ала:

+7 800-555-92-10
+7 843-21-21-200

+7 966-240-53-96

dumrt-hajj.ru

Казан шәһәре, Тукай урамы, 3 йорт

@hajj_dum_rt

РЕКЛАМА. 12+

ИШЕК КАГУ ӘДӘБЕ

- Дивар янында басып торырга кирәк
- Ишеккә каршы басып торырга ярамый
- Ишек кагар алдыннан «сөбеханәллаһ» һәм «әлхәмдүлилләһ» дип әйтергә
- Ишек каккач та сәлам бирергә
- Өй эчендәге кешеләрнең сөйләшүләрен яшерен рәвештә тыңлап тору тыелган
- Сәлам биргәч, йортка керергә рөхсәт сорарга
- Рөхсәт итсәләр, керергә ярый, рөхсәт итмәсәләр, көтеп торырга ярамый, китеп барырга кирәк
- «Кем анда?» – дип сорагач: «Мин», – дип җавап бирергә ярамый, исемеңне атарга кирәк

ЮЛ ЧАТЫНДА ЯШӘҮЧЕ КЕШЕНЕҢ ӘДӘБЕ

- Үтеп баручыларны күзәтмәскә
- Хаксызга рәнҗетелгән кешене күрсәң, аны якларга тырышырга
- Ярдәм сораучыларга ярдәм итәргә ашыгырга
- Көчсезләргә ярдәм итәргә
- Адашканнарга юл күрсәтергә
- Сәлам бирүчеләргә каршы сәлам бирергә
- Садака сорап килгәннәрне буш кул белән кире борып җибәрмәскә
- Як-якка каранмаска
- Хикмәт белән яхшыга өндәргә һәм тыелганнардан тыелырга
- Әгәр кем дә булса начар гамәл кылуда катгый торса, аны куркытып яки көч кулланып начар гамәлдән тыярга кирәк
- Сүз йөртүченең сүзләрен тыңламаска
- Кешеләрдә кимчелек эзләмәскә
- Кешеләр хакында начар уйламаска һәм, ни күрсәң дә, яхшыга юрарга

КЕШЕЛӘР БЕЛӘН ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ ӘДӘПЛӘРЕ

- Бинага кергәч тә яисә бер төркем кеше белән очрашкач, иң элек сәлам бирергә, аннан соң башкаларга комачауламый торган урынга барып утырырга кирәк
- Кешеләр арасыннан узганда башкаларга комачау итмичә үтәргә кирәк
- Утырыр урын эзләп тапкач та, яныңда утыручыларга аерым сәлам бирергә кирәк
- Әгәр таныш булмаган кешеләр арасында булырга туры килсә, кирәкмәгән әңгәмәләрдән читтә торырга, аларның сөйләшүләренә катышмаска кирәк. Әгәр таныш булмаган кешеләр сүгенү сүзләрен кулланса, ишетмәмешкә салышырга кирәк
- Андый кешеләр белән, кискен ихтыяҗ булмаган очракта, очрашмау ягын кайгыртырга кирәк
- Кешеләрне түбәнсетеп караудан сакланырга кирәк. Югыйсә, бу сине һәлакәткә илтүе бар, чөнки син әһәмият бирмәгән ул кешеләрнең синнән яхшырак һәм тәкъварак булу ихтималы бар
- Бай кешеләр арасында булганда, аларга сокланып карау килешми, чөнки бу дөнья һәм дөньяда булган барлык нәрсә Аллаһы Тәгалә өчен бернинди кыйммәткә ия түгел
- Дөньяви әйберләргә зур әһәмият бирмәскә кирәк, югыйсә, дөньяви байлыкка ия булып, Аллаһы Тәгалә каршында түбән булган кешеләрне дә өстен күрергә мәҗбүр буласың
- Бай кешеләрнең малларын кулана алу өчен динне кулланырга ярамый. Әгәр моның өчен динне кулланасың икән, алар алдында үзеңнең дәрәҗәңне югалтасың, хөрмәт ителми башлыйсың
- Шул ук вакытта хәлле кешеләргә карата дошманлык күрсәтү дә ярамый. Югыйсә, алар да сиңа дошманлык күрсәтәчәкләр, соңыннан алар белән көрәшергә көчең дә, мөмкинлегең дә булмавы бар
- Әмма Аллаһы Тәгалә каршында аларны дошман күрү – бөтенләй башка нәрсә. Кешеләрнең начар гамәлләре синдә нәфрәт уятырга тиеш
- Кешеләргә мәрхәмәт һәм шәфкать белән карарга кирәк
- Алар үзләренең яратулары хакында сөйләгәне, сыйлаганы, йөзеңә карап көлгәне һәм мактаганы өчен хәлле кешеләр янына еш барырга кирәк түгел. Акыллы кеше мондый игътибарга бирешмәс, чөнки мондый мөнәсәбәтнең ихлас булу очраклары бик сирәк
- Әгәр кеше байлар арасында үзенә рәхәт һәм хозур тапса, Аллаһы Тәгалә аны шул кешеләр кулына калдырыр, һәм аны апачык һәлакәт көтәчәк
- Бай кешеләрнең син югында да сиңа карата син яннарында булган кебек мөнәсәбәттә булуларын көтмәскә кирәк, бу һич мөмкин түгел
- Бай кешеләрнең байлыкларына комсызланып карарга кирәк түгел, югыйсә, кеше үз абруен һәм иманын югалтачак
- Бай кешеләр белән үзеңне тәкәббер тоту да килешми
- Әгәр ярдәм сорап мөрәҗәгать ителгән бай кешеләрнең берсе кире какмыйча ярдәм итсә, ул яхшы иптәш. Шулай да, ярдәм итүдән баш тарткан кешеләрне дә тәнкыйтьләргә ярамый, югыйсә, синең хөкем итүең аларда нәфрәт уятырга мөмкин
- Әгәр кемнең дә булса үгет-нәсыйхәткә колак салачагына өмет юк икән, бу очракта киңәш итүдән тыелырга кирәк. Югыйсә, алар сезнең нәсыйхәтне тыңламый гына түгел, аларда сезгә карата нәфрәт тә уянырга мөмкин
- Әгәр кем дә булса берәрсенә ярдәм итсә яки аны мактаганнарын ишетсә, моның Аллаһы Тәгаләдән икәнен белергә кирәк һәм шунда ук Раббыңны мактау белән искә алырга ашыгырга, Аңа кешеләр кулына калудан сыенып дога кылырга кирәк
- Әгәр кем дә булса аңа золым кылса, аның хакында начар сүз әйтсә, гайбәт таратса, аны үпкәләтерлек берәр нәрсә әйтсә, ул кешенең тәкъдирен Аллаһы Тәгаләгә тапшырырга һәм Аннан сезне дошманнарга әйләнүдән саклавын сорарга кирәк. Аларны хөкем итү һәм тәнкыйтьләүдән тыелырга кирәк, чөнки моннан бернинди дә файда булмаячак, киресенчә, дошманлыкларын гына арттырачак. Андый кешеләргә үпкәләүдән дә файда юк. Иң яхшысы – кешеләрнең шулай сөйләвенә сәбәп булган гөнаһларың өчен тәүбә итү, Аллаһы Тәгаләдән истигъфар сорау
- Тәнкыйтьне тыңларга, ләкин буш сүзләргә игътибар итмәскә кирәк.

Имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең «Әдәпләр» китабыннан



«КОЛЫМ ГАМӘЛЕН МИНЕМ ӨЧЕН КЫЛМАДЫ»

Фото: shutterstock.com

Аллаһы Тәгаләнең Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дәреслектә, фәрештәләр Аллаһы Тәгаләнең колларыннан булучы бер кешенең гамәлен күтәрерләр, хәтта Аллаһы Тәгалә теләгән урынга илтеп җиткергәнчегә кадәр, ул гамәлне күпкә санарлар, аны пакьләрләр.

Аллаһы Тәгалә ул фәрештәләргә вәхи кылыр: «Дәреслектә, сез Минем колымның гамәлен саклаучылар һәм Мин ул колның күңелендә булган нәрсәне Күзәтүче. Дәреслектә, бу колым үзенең гамәлен ихластан һәм Минем өчен кылмаган. Сез аны Сиҗҗингә (Сиҗҗин – имансызларның, монафикъларның, гөнаһ кылучыларның гамәлләре язылган китап) языгыз». Янә ул фәрештәләр тагын бер колның гамәлен күтәрерләр. Ул гамәлне, Аллаһы Тәгалә теләгән урынга җиткергәнгә кадәр, аз һәм кечкенә дип санарлар. Аллаһы Тәгалә аларга вәхи кылыр: «Дәреслектә, сез колымның гамәлен саклаучылар, Мин ул колның нәфесендә булган нәрсәне Күзәтүчемен. Дәреслектә, бу колым Минем өчен хас һәм саф булды, аның гамәлен югары күкләргә языгыз».

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

«Әгәр ул** [гамәл] **яхшы бернәрсә икән, Ул аны** [савап ягыннан] **арттырыр һәм Үз хозурыннан бик зур әҗер бирер».

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:40

КАБЕР ГАЗАБЫНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бер кеше кабер газабыннан котылырга теләсә, аңа дүрт төрле нәрсәне үтәү һәм дүрт нәрсәдән саклану лязем (тиеш) булыр. Тиешле булган дүрт нәрсә: намазларны уку, садаканы бирү, Коръән уку, тәсбихләрне күп кылу, чөнки бу нәрсәләр каберне яктырта һәм киң кыла. Әмма кабер газабыннан саклана торган дүрт нәрсә: ялган, хыянәт, сүз йөртү һәм бәвелдер».

Дәреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бәвелдән (сидектән) сакланыгыз, чөнки кабер газабының күбесе бәвелдән сакланмаганнандыр».

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дәреслектә, Аллаһы Тәгалә сезгә дүрт нәрсәне мәкруһ кылды: намазда буш эш, Коръән укыганда уйнау, уразада яман сүз сөйләү, кабер янында көлү».

Мөхәммәд бине Сәмәктән риваять ителгән: Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм зиратка караган һәм: «Бу кабернең тик торуы сезне алдамасын. Ни гаҗәп, ул каберләрдә кайгылылар күп булды. Янә сезне каберләрнең тигезлеге алдамасын, ни гаҗәп, ул кабердәге кешеләрнең бер-берсеннән аерылуы каты булды. Акыллы кешегә кабергә кергәнче үк, каберне күп итеп зикер кылу тиешледер, – диде».

ҖӘБРАИЛ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМНЕҢ СҮЗЛӘРЕ

Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламне чакырып, аны җәннәткә җибәрде. Аллаһы Тәгалә аңа: «Җәннәткә һәм аның әһеленә әзерләнгән нәрсәләргә кара», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам кайтып: «Синең куәтең белән ант итәм, ул җәннәт хакында ишетүче анда керергә теләр», – дип әйтте. Моннан соң Аллаһы Тәгалә аны төрле авырлыклар белән чолгап алды һәм: «Ул җәннәткә кайт һәм аңа кара», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам кайтты һәм: «Синең көчең белән ант итәм, дәреслектә, ул җәннәткә берәү дә кермәс дип куркам», – диде.

Соңыннан Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламне җәһәннәмгә җибәрде. Аллаһы Тәгалә аңа: «Җәһәннәмгә һәм аның әһелләренә әзерләнгән нәрсәләргә кара», – дип әйтте. Җәбраил галәйһиссәлам Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә кайтып: «Синең көчең белән ант итәм, ул җәһәннәм хакында ишеткән кеше беркайчан да анда кермәскә тырышыр», – диде. Моннан соң Аллаһы Тәгалә аны көчле теләкләр белән чолгап алды һәм Җәбраил галәйһиссәламгә: «Ул җәһәннәмгә кайт һәм аңа кара», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам кайтты һәм: «Синең олуглыгың һәм гыйззәтең белән ант итәм, анда кермичә берәү дә калмас дип куркам», – дип әйтте.

«Тәнбиһүл гафилин»
китабыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (331) февраль, 2023 | раҗәб-шәгъбан, 1444

Куныр авылы мәчете. Фото авторның шәхси архивыннан

ТӘРБИЯ ЯРАЛАДЫР ТӘРБИЯДӘН

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Кышның гаҗәеп матур бер көнендә, Балтач районының иң ерак, үзәктән 40 чакрым ераклыктагы бер төбәгендә, күпләрнең исендә мәңге калырлык, әле озак вакытлар, кабат-кабат сагынып сөйләрлек үзгә, матур, эчтәлекле зур бәйрәм – Куныр авылы мәчете ачылуга 30 ел тулуга багышланган авыл җыены булып узды. Авыл халкының матур итеп бәйрәм итүен һәм бер-берсенә карата булган мөгаләмәнең җылы, эчкерсез, якты булуын күреп сокланып кайттык без ул көнне. Кунырлыларның авызында бары бер сүз: «Авылыбыз бик матур, кешеләре тырыш, ихлас шул безнең, Аллаһыга шөкер! Һәр кешесе иманлы, якты күңелле булганга, эшләребез дә уң». Авызларында зарлануның эзе дә юк. Кемнәндер ярдәм сорап утыру да ят аларга. Булганына шөкер итеп, матур итеп яши беләләр кунырлылар.

Куныр авылында үткән чарадан матур мизгелләр. Фото авторның шәхси архивыннан

СОКЛАНМЫЙ МӨМКИН ТҮГЕЛ

Кунырның сөйкемле абый-апаларына, аларның дини, дөньяви эшчәнлекләренә сокланмый мөмкин дә түгел. Ул көнне бәйрәм сәхнәсеннән яңгыраган һәр чыгышта шушы җирлек кешесе, шушы төбәкнең тырыш, булган, уңган игелекле авылдашлары, хезмәткәрләре, җитәкчеләре макталды. Алар башкарган һәрбер хезмәт саналып, барлап үтелде. Дөресе дә шулай бит, ерактан бәйрәмгә кунакка килгән кешеләрнең күңеле булсын яки менә безнең башкарган хезмәтләрне күреп шаккатсыннар әле дип бер-берсен мактатып, мактанышып утыруга (вакыт сарыф итүгә) мөмкинлек тә, җирлек тә бирелмәде әлеге кичәдә. Үзләре дә, районда беренчеләрдән булып төзелгән мәчет эшчәнлегендәге яңалыкларны: балаларга һәм өлкәннәргә дини белем бирүне, үз куллары белән башкарган мәчет ремонтын, алдагы планнарны гади генә итеп сөйләп, аңлатып үттеләр. Кыскасы, бәйрәм чарасы эшлекле, эчтәлекле булды, хезмәт кешесен, дин юлындагыларны олылау, хөрмәтләү төсмерен алды һәм күпләрнең күңелләрендә бу авылга, аның халкына соклану катыш гаҗәпләну дә өстәлде. Ни өченме? Авылның ак яулыклы, ак күңелле, саф йөрәкле алты апасы (әбиләре дияргә тел бармый) авылны да, мәчетне дә «үз кулларында тота» икән! Балаларны, өлкәннәрне мәчеткә чакыру дисеңме, дини белем алуны оештырумы, вәгазь кичәләре үткәрүме, дини чаралар уздырумы, мәчетне карап һәм тәртипләп тотумы – барысы да Тәгъзимә апа Сәгытдинова җитәкчелегендәге Люция, Әлфия, Зөлфия, Рәмзия, Миләүшә апалар кулында икән! Кемнәрдер башлап йөрмәсә һәм кемнәрдер аларга иярмәсә, авылның 30 дан артык баласын, алардан ике-өч тапкырга артык булган өлкәннәрне мәчеткә тарта алырлар идеме икән?! Авылның имамы Нуретдин хәзрәт тә аларга ышана, һәр эшләрен яклап, хуплап тора. Тәгъзимә апаның һәр сүзе үтемле, мәгънәле булганга, түрә-кара янына да аны йөртәләр икән. Сүзен сүз итәргә өйрәнгән, 70 яшен үтеп баручы бу авыл апасының кайда эшләп ялга чыгуы белән дә кызыксындым. Казахстаннарда йөреп, кабат туган якларына кайтып төпләнгән Тәгъзимә апа чит җирләрдә санитар-эпидемиологик станциясендә эшләгән икән. Шуңадырмы,

мәчеткә өйлә намазына килгән һәркем биредәге чисталыкка, пөхтәлеккә игътибар итми калмагандыр. Кыш булуына карамастан юылган тәрәзәләр, сафлык бөркеп торган паласлар, тәрәзә төбен тутырган шау чәчәкле гөлләр – барысы да мәчетне олылауга, зурлауга ишарә икәненә төшенү артык кыен булмады. Йөзләреннән нурлар бөркелеп торучы бу апалар белән ахырдан калып шактый сөйләшеп утырдык без.

Балтач районы имамнарының ай саен бер мәхәлләгә җыелып, үткән айдагы эшчәнлеккә хисап тоту, киләсе айга планнар кору, үтемле вәгазь сөйләү, булган сорауларга җавап бирә торган бер матур гадәтләре бар. Балтач районы мөхтәсибе Җәлил хәзрәтнең бик кирәкле, төгәл һәм уйланып эшләгән бу адымы хуплауга лаек. Әнә шул имамнарның да нәкъ менә Куныр авылы мәчетенең 30 ел-лык юбилеена туры китереп чакырылуы – бу чараның эчтәлеген тагы да баетты, тирәнәйтте, ныгытты.

ИМАНЛЫ БАЛАЛАР – ЯКТЫ КИЛӘЧӘГЕБЕЗ

Мәктәптә 20 елдан артык әхлак дәресләре укытылып килү дә уңай нәтиҗәләрен бирә. Бүгенге көндә 2 нче класстан алып, 6 нчы класска кадәр «әхлак түгәрәге» эшли. Дәресләрне Гөлҗамал ханым укыта. Куныр балалары белән бергә Дорга, Шода балалары да халкыбызның үткән мирасын, гореф-гадәтләрен, тарихын тырышып үзләштерәләр. Мәктәптәге 99% баланың мәчеткә йөреп дини белем алуын ишеткәч, ак көнләшү белән көнләшеп куйдым. Менә булдыралар болар!

Бәйрәм чарасы балалар бакчасы һәм мәктәп яшендәгеләрнең чыгышы белән башланып китте. Авыл мәдәния йортында үткәрелгән бу чарада бәйрәм сәхнәсеннән балалар Коръән сүрәләре, кыска догалар, хәдисләр, гыйбарәле сүзләр сөйләде. Коръән укыганда дөрес итеп сузулар, тәҗвид кагыйдәләрен исәпкә алып яңыраган сүрәләрне ишетеп берәү дә битараф калмагандыр. Бәйрәмнең асыл мәгънәсе булып яңыраган Коръән аятләре залда утыручыларны үз эченә бөтереп алып кереп китәрлек иде. Күпләрнең күзләрендә яшь тамчылары җемелдәде. Үтә дә камил итеп төзелгән сценарийда бер пауза да булмыйча, бер сулыш, бер тын белән узды. Тыңлаучылар «Аһ!» итте. Сөбхәналлаһ! Афәрин, балалар!

Бәйрәмгә Казанның «Ислам дине кабул итүгә 1000 ел» исемендәге югары мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин да килгән иде, аңа да балаларның чыгышы бик ошады. Хәзрәтне бу балаларны кем әзерләве кызыксындырды. Залга мөрәҗәгать итеп: «Бу балаларны әзерләүчеләрне күрәсе килә иде», – диде ул. Залда янәдән Тәгъзимә апа җитәкчелегендәге биш апа торып баскач, хәзрәт берара сүзсез калды. Апаларның икесе сыер савучы булган, калганнары укытучы, фельдшер, соцаль хезмәткәр булып эшләгән. Ялга чыккач, «Ислам дине кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсәнең Балтач филиалында белем туплап, балаларга дини белем бирүгә алынганнар. Аллаһы ризалыгы өчен балалар арасында мәш килеп йөрүче бу апалардан да кадерлерәк кем булды икән бу минутларда?! Юктыр, мөгаен. «Без бу балаларда, аларның чыгышында матур киләчәгебезне күрәбез. Аларда бу авылның дини йөзе дә күренә. Сокланырлык хезмәт башкарасыз!» – диде Ильяс хәзрәт.

Балалар чыгышыннан соң сәхнә түренә хөрмәтле кунаклар узды. Җөмһүриятебезнең Баш казые, район мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев бәйрәм чарасын ачып: «Бу балаларның чыгышында безнең өчен вәгазь дә, сокланырлык ихлас дини дәрес тә, эчкерсез аралашу да булды. Инде вәгазь сөйләп тормасак та буладыр», – диде. Могҗизага тиң бу күренешне күреп, Җөмһүриятебезнең мөфти урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов тә күтәреп һәм хуплап алды: «Балалар авызыннан яңыраган «Бисмилләһ» сүзләре үзе генә дә ни тора. Һәр сүрә алдыннан «Бисмилләһ» әйткән бу балаларның сөйкемле йөзләрен күреп, балаларның һәр укыган аятеннән безнең калебләр нечкәрә, ихласлык, мәрхәмәт арта», – дип соклануын яшермәде. Илфар хәзрәтнең кереш сүзе дә балалар чыгышының тәэсире белән башланып китте. Аннан соң ул дин юлында булучыларга үгет-нәсыйхәтләрен җиткерде. Тын алырга да кыенсынып, Илфар хәзрәтнең сөйләгәнен «йотып» утыручылар арасында бер мин генә булмаганмындыр. Үтә дә тәэсирле итеп, Коръән сүрәләреннән дәлилләр китереп сөйләде Казан хәзрәте. Ихлас икәнлеге йөзенә чыккан Илфар хәзрәтне тагын да тыңлыйсы килеп калды.

ИҢНЕ-ИҢГӘ КУЕП БАШКАРЫЛГАН ЭШЛӘР

Кичәнең түренә чакырылган Хәмит абый Гәрәев сүзләрендә дә авылдашларына хөрмәт, аларны олылау сизелде. Шундый яратып сөйләде ул үз авылы кешеләре турында. Иңне-иңгә куеп, мәчет төзелешендә эшләгән кешеләрне үз чыгышында кабат кайта-кайта искә алып үтте ул. Ашыкмыйча, шапырынмыйча, гади, үтемле итеп фикерен җиткерде хезмәт ветераны. Түзмәдем, ахырдан Хәмит абый янына барып, кулын кысып «Рәхмәт!» әйттем. Гади халыкны данлаганга, үз авылында гадел түрә булганга, элеккеге зират өстенә салынган амбарларны күчереп салдырганга һәм тагын башка бик күп игелекле эшләренә рәхмәтләремне җиткердем. Калганнарга да күмәк хуҗалыкның элеккеге җитәкчесе Хәмит абый Гәрәевның чыгышы хуш килгәндер дип уйлыйм.

Тагын бер шатлану катыш гаҗәпләнүем: бүгенге күмәк хуҗалык рәисе Зиннур әфәнденең башына түбәтәен киеп, кичәнең башыннан ахырына кадәр халык арасында булуы иде. Өйлә намазында да мәхәлләдән аерылмыйча алар белән бергә намазда катнашып, җәмәгатьтән бер минутка да читкә китмичә, халык арасында булуына йөрәк шатланып куйды. Бәйрәм өстәле әзерләп кунакларны сыйлау да аның тәкъдиме белән эшләнгән. Менә авылга иман кемнәр аша иңә икән! Кешегә йөз белән борылуга әллә ни дә кирәк түгел кебек. Намазлыкка басып, сәҗдәләргә китеп, Аллаһыга мөрәҗәгать итүче җитәкчеләр белән эшләү һәркемгә дә насыйп булса иде, дип теләдем мин. Иманлы җитәкче булганда гына эшләребезнең уң, гамәлләребезнең хәерле булуын инде раслап торасы да юк бит.

Эшләре белән дә, кылган гамәлләре белән дә үрнәк булган әлеге ак авыл, якты авыл – Куныр турында җылы хәтирәләр белән кайтыр юлга чыктык. Мәчетләренә 30 ел тулуны бәйрәм итү чарасында катнашып, күпме җылылык, наз алып, иланы бер биеклеккә күтәрелеп таралыштык. Әле тагын бу авылга барасы, аның нурлы йөзле кешеләре белән тизрәк аралашасы килеп калды. Насыйп булса иде, ИншәАллаһ!

Рәҗәп Бәдретдинов,
Балтач районы әхлак укытучыларының методик берләшмә җитәкчесе

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (331) февраль, 2023 | раҗәб-шәгъбан, 1444

Сөннәтче бабай

Фото: shutterstock.com

(Дәвамы. Башы алдагы санда)

Жыелган икмәкне сатып, карчыгына күлмәк, алъяпмалык, үзенә күлмәк, ыштан, рамазан никадәр ерак булса да, «санаулы көн үтәр» дип, мәсҗедтә авыз ачтырырга дип, ике кадак хөрмә алып, мәәззингә бирә иде. Шуннан соң ул тагы иске торышы берлән, тагы киләсе елның сөннәт вакытыны көтү өмете берлән яши иде.

Шулай итеп еллар үтә, яшьләр өйләнә, яңа балалар, яңа сөннәтләр җитә, анлар үтә; анлар артыннан килә торган буынның баласы-чагасына рәт җитә иде. Яшьләр картая, картлар үлә, еллар үтә иде. Ләкин бу үткән еллар, аның яшен картайтмаган кеби, аның битенә яңа җыерчыклар да чыгармый вә аның билен тагы бөкрәйтми иде. Ул, дөнья үтүен сизмәгән кеби, һаман элгәреге Сөннәтче бабай булып тора иде.

* * *

Тыйб гыйлеменчә мәгълүм: кешенең тәнендәге канының куелыгы вә сыеклыгы, вә ул канның агуы елның фасыллары берлән бик зур мөнәсәбәте бар. Кыш көннәрендә инсаннарның каннары бөрешкән, куеланган хәлдә була. Ул тамырлар буенча акыртын гына, һаваланып кына ага. Кыш көнендә бер-бер әгъза киселсә, яисә тамыр өзелсә, кан, касәдән авыр-авыр чыга торган куе каймак кеби, акыртын гына ага; җәрәхәт тиз бетәшә. Көннәр озая башлап, кояш күбрәк җылыта башлагач, урамнарда сулар җыела башлагач, адәм тәнендәге кан да, кояш җылысында эрегән кар кеби, языла башлый. Көн җылынган саен ул сыегая-сыегая килә. Май числосында ул тәмле-татлы язгы сөт кеби була. Шуның өчен ул вакыттта кешеләр үзләрен яшәргән кеби хис итәләр, аркаларыннан бик зур йөкне ташлаган кеби, җиңеләеп калалар. Бу вакыт кан, үзеннән-үзе, кыш буе җыелган бозык, начар каннарны куа башлый. Җәй җитеп, көн кызуланган саен кан сыекланганнан-сыеклана бара. Кеше тәнендәге торасы килмәгән кеби, адәмнең эчендә кайный, яңлышлык берлән кул-баш киселсә, бик күп кан әрәм була. Һавалар суыгая башлап, яшел үләннәр кырау күргәч, кан тагы, сөт өстенә утыра торган каймак кеби, акыртын гына утыра, куера башлый. Кыш якынлашкан саен аның куеруы арта, шуның өчен гыйльме тыйб ияләре кан алдыру, мөгез салдыруның вакытларын елның фасылы берлән тәгъйин итәләр (*туры китерәләр – ред.*). Һичбер вакытта, аерым бер авыруы булмаса, канның сыекланган вакытында тамырын кисеп, адәмнең шашкан, чыгарга көтеп кенә торган канын әрәм итмиләр. Шуның кеби үк, кыш көнендә, куерган, утырган канны йокысыннан уятып, аның ага торган юлын бозмыйлар, аның буасын җырмыйлар. Анлар кан алдыру өчен һәрвакыт кыш буе җыелган начар, бозык каннарны, канның үзенең чыгарып-иркенләнеп калырга теләгән яз көнен ихтыяр итәләр. Шул яз көнендә, көннәр җылынып җиткәч кенә, тамырдан кан алалар, мөгез салалар.

Елның фасылларының канның агуына, канның куелыгы-сыеклыгына тәэсире булган кеби, айның, көннең дә тәэсире юк түгел. Айның тулысында кан тулы булганга, кан алу өчен куркынычсыз түгел. Канны туктату авыр булып, теләртеләмәс, күп кан чыгу ихтималы бар. Айның башында яшь тамырга өйрәнеп бетмәгән каннар чыгып китүләре ихтималы булганга, таза канның чыгып, карт канның калу шөбһәсе бар. Шуның өчен канны алдыруны тулы ай кителә башлагач муафикъ күргәннәр. Айның унтугызынчы, егерме беренче көннәрен бигрәк мәслихәткә санаганнар.

Көннең исеме берлән, көннең вакыты берлән дә канның агуының, әлбәттә, мөнәсәбәте бар. Ләкин көннәр һәммәсе дә Аллаһы Тәгаләнең көне булганга, бу мөнәсәбәтләрне тәгъйин итәргә тыйб галимнәре ирешә алмаганнар. Аллаһы Тәгалә бу серне анлардан яшергән. Шулай булса да, көннәр өчен дә сәбәпләре мәгълүм булмаса да, сишәмбе вә якшәмбе көннәрне артык күргәннәр.

Безнең Сөннәтче бабай Сәлман Фарси хәзрәтләреннән мирас тарикы берлән сөннәтчелекне алса да, Әбүгалисина хәзрәтләре тарафыннан тыйб гыйльме, гыйльме симия вә гыйльме кимиягә иҗазәт алмаганга, әлбәттә, тыйб гыйльменең бу кадәр нечкәлекләрен белми иде. Ләкин исәпсез-хисапсыз еллар хәзрәтләр, муллалар, мәәззиннәр берлән катнашу, анларга исәпсез-хисапсыз мәртәбә мөгез утырту, иксез-чиксез анларның каннарын алу аңар зур тәҗрибә биргән вә шул кагыйдәләргә аны да олыштырган иде. Ул да һичбер вакыт көз кан алмый, кыш мөгез салмый иде. Ул да һичбер вакыт айның тулысында мөгезен истигъмаль итми (*кулланмый – ред.*), җәйнең кызуында кан балтасын тамырга сукмый иде. Ул да һичбер вакытта баш көнендә, яисә шимбә көнендә кан эшенә тотынмый иде. Ул кан өчен вакытын, көнен исәпләп, аен, сәгатен саклап тора иде.

Менә шул көн җитә башлагач, хәзрәт, мәхдүм аркылы, яисә хезмәтче аркылы, Сөннәтче бабайга: буш көн (сишәмбе көн) кан алырга керсен, дип, хәбәр иттерә иде. Сөннәтче бабай мөгезләрен җылы суда кат-кат юа, кан тамырына чаба торган балтасын үткәрә, мөгез астына суга торган пәкесен ныграк очлый иде. Ул шул көн җиткәч, тагы, кияү булып кергәндәге күлмәкен, Кәбир хәзрәттән калган әдрәс камзолын, мәхдүмәдән килгән кәләпүшен киеп, ап-ак чүпрәккә төргән мөгез салу әйберләрен күтәреп, иртәге чәйне эчкәч тә хәзрәткә китә иде. Хәзрәт аны үзе каршы ала, остазбикә тасларга җылы суларны үзе хәзерли иде.

(Дәвамы киләсе санда)

Гаяз Исхакый

ХӨРМӘТЛЕ РАДИОТЫҢЛАУЧЫЛАР!

«Азан» радиосын **azan.fm** сайтында яки **«АЗАН» РАДИОСЫ** рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

ANDROID ӨЧЕН: **IPHONE ӨЧЕН:**

САЙТ:	ВКОНТАКТЕ:	ТЕЛЕГРАМ-КАНАЛ:	ПОЧТА:	ТЕЛЕФОН:
azan.fm	azanfm	azanfm	radio@azan.fm	8 (843) 598-09-43

ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ

0:00	Коръәни Кәрим 0+
6:05	Коръән тәфсире 12+
6:25	Көндәлек догалар 6+
6:30	Тынычлык тәгәлимате 12+
7:05	Таян Аллаһка 6+
7:20	Хәзрәткә сорау 12+
7:30	Иман тәме 12+
7:50	Миллият сүзлеге 6+
7:55	Гыйбрәтле кыйссалар 6+
8:05	Бәхет тулы йорт 12+
8:30	Күңелдән күңелгә 12+
8:50	Шәхесләргә шәрехләр 6+
9:00	Рухи хәзинә 6+
9:15	Гыйбадәте Исламия 6+
9:30	Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
9:40	Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
10:40	Миллият сүзлеге 6+
10:45	Көндәлек догалар 6+
10:50	һәр яхшы сүз – садака 6+
11:00	40 хәдис 6+
11:20	Аллаһының 99 исеме 6+
11:30	Мәчетләребез тарихы 6+
11:40	101 вәгазь 12+
12:00	Өйләгә азан 0+
12:10	Гыйбадәте Исламия 6+
12:25	Миллият сүзлеге 6+
12:30	Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+
14:00	Гыйбадәттә сәгадәт 12+
14:10	Әхлак баскычлары 6+
14:30	Пәйгамбәрләр тарихы 12+
14:45	Сөннәт юлы 12+
15:05	Коръән тәфсире 12+
15:25	Көндәлек догалар 6+
15:45	Бәхет тулы йорт 12+
16:05	Миллият сүзлеге 6+
16:10	Гыйбрәтле кыйссалар 6+
16:20	101 вәгазь 12+
16:40	Күңелдән күңелгә 12+
17:00	Шәхесләргә шәрехләр 6+
17:10	Гыйбадәте Исламия 6+
17:30	һәр яхшы сүз – садака 6+
17:40	40 хәдис 6+
19:30	Әдәбият күрке әдәп 6+
19:45	Миллият сүзлеге 6+
20:00	Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
20:20	һәр яхшы сүз – садака 6+
20:30	Нәниләргә нәсыйхәт 6+
20:35	Пәйгамбәрләр тарихы 12+
20:50	Көндәлек догалар 6+
21:10	Мәчетләребез тарихы 6+
21:30	Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
21:50	Хәзрәткә сорау 12+
22:00	Гыйбадәттә сәгадәт 12+
22:10	Әхлак баскычлары 6+
22:37	Миллият сүзлеге 6+
22:45	Аллаһының 99 исеме 6+
23:00	Коръәни Кәрим 0+

ҖӨМГА

0:00	Коръәни Кәрим 0+
6:00	Җомга тәбриге 12+
6:05	Коръән тәфсире 12+
6:25	Көндәлек догалар 6+
6:30	Тынычлык тәгәлимате 12+
7:05	Таян Аллаһка 6+
7:20	Хәзрәткә сорау 12+
7:30	Иман тәме 12+
7:50	Миллият сүзлеге 6+
7:55	Гыйбрәтле кыйссалар 6+
8:05	Бәхет тулы йорт 12+
8:25	Җомга тәбриге 12+
8:30	Күңелдән күңелгә 12+
8:50	Шәхесләргә шәрехләр 6+
9:00	Рухи хәзинә 6+
9:15	Гыйбадәте Исламия 6+
9:30	Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
9:40	Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
10:00	Җомга тәбриге 12+
10:40	Миллият сүзлеге 6+
10:45	Көндәлек догалар 6+
10:50	һәр яхшы сүз – садака 6+
11:00	40 хәдис 6+
11:20	Аллаһының 99 исеме 6+
11:30	Мәчетләребез тарихы 6+
11:40	101 вәгазь 12+
12:00	Өйләгә азан 0+
12:10	Гыйбадәте Исламия 6+
12:25	Миллият сүзлеге 6+
12:30	Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+
14:00	Гыйбадәттә сәгадәт 12+
14:10	Әхлак баскычлары 6+
14:30	Пәйгамбәрләр тарихы 12+
14:45	Сөннәт юлы 12+
15:00	Җомга тәбриге 12+
15:05	Коръән тәфсире 12+
15:25	Көндәлек догалар 6+
15:45	Бәхет тулы йорт 12+
16:05	Миллият сүзлеге 6+
16:10	Гыйбрәтле кыйссалар 6+
16:20	101 вәгазь 12+
16:40	Күңелдән күңелгә 12+
17:00	Шәхесләргә шәрехләр 6+
17:10	Гыйбадәте Исламия 6+
17:30	һәр яхшы сүз – садака 6+
17:40	40 хәдис 6+
19:30	Әдәбият күрке әдәп 12+
19:45	Миллият сүзлеге 6+
20:00	Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
20:20	һәр яхшы сүз – садака 6+
20:30	Нәниләргә нәсыйхәт 6+
20:35	Пәйгамбәрләр тарихы 12+
20:50	Көндәлек догалар 6+
21:10	Мәчетләребез тарихы 6+
21:30	Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
21:50	Хәзрәткә сорау 12+
22:00	Гыйбадәттә сәгадәт 12+
22:10	Әхлак баскычлары 6+
22:37	Миллият сүзлеге 6+
22:45	Аллаһының 99 исеме 6+
23:00	Коръәни Кәрим 0+

ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

0:00	Коръәни Кәрим 0+
6:05	Коръән тәфсире 12+
6:25	Көндәлек догалар 6+
6:30	Тынычлык тәгәлимате 12+
7:05	Таян Аллаһка 6+
7:20	Хәзрәткә сорау 12+
7:30	Иман тәме 12+
7:50	Миллият сүзлеге 6+
7:55	Гыйбрәтле кыйссалар 6+
8:05	Бәхет тулы йорт 12+
8:30	Күңелдән күңелгә 12+
8:50	Шәхесләргә шәрехләр 6+
9:00	Рухи хәзинә 6+
9:15	Гыйбадәте Исламия 6+
9:30	Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
9:40	Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
10:40	Миллият сүзлеге 6+
10:45	Көндәлек догалар 6+
10:50	һәр яхшы сүз – садака 6+
11:00	40 хәдис 6+
11:20	Аллаһының 99 исеме 6+
11:30	Мәчетләребез тарихы 6+
11:40	101 вәгазь 12+
12:00	Өйләгә азан 0+
12:10	Гыйбадәте Исламия 6+
12:25	Миллият сүзлеге 6+
12:30	Кәлам Шәриф. Тәрҗемә 12+
14:00	Гыйбадәттә сәгадәт 6+
14:10	Әхлак баскычлары 6+
14:30	Пәйгамбәрләр тарихы 12+
14:45	Сөннәт юлы 12+
15:05	Коръән тәфсире 12+
15:25	Көндәлек догалар 6+
15:45	Бәхет тулы йорт 12+
16:05	Миллият сүзлеге 6+
16:10	Гыйбрәтле кыйссалар 6+
16:20	101 вәгазь 12+
16:40	Күңелдән күңелгә 12+
17:00	Шәхесләргә шәрехләр 6+
17:10	Гыйбадәте Исламия 6+
17:30	һәр яхшы сүз – садака 6+
17:40	40 хәдис 6+
19:30	Әдәбият күрке әдәп 12+
19:45	Миллият сүзлеге 6+
20:00	Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
20:20	һәр яхшы сүз – садака 6+
20:30	Нәниләргә нәсыйхәт 6+
20:35	Пәйгамбәрләр тарихы 12+
20:50	Көндәлек догалар 6+
21:10	Мәчетләребез тарихы 6+
21:30	Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
21:50	Хәзрәткә сорау 12+
22:00	Гыйбадәттә сәгадәт 12+
22.10	Әхлак баскычлары 6+
22:37	Миллият сүзлеге 6+
22:45	Аллаһының 99 исеме 6+
23:00	Коръәни Кәрим 0+

*** Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый**

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррир: **Юлдашева А. И., Гәрәева Л.Р., Ситдикова Г.Р.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
Электрон адресы: shura@huzur

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
НӘШИР: «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2586.
График буенча – 20 нче февраль 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 168,90 сум.
Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 22 нче февраль көнне таратыла.

НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

МАРТ 2023 / КАЗАН

Көн	Көн исеме	ИРТӘНГЕ НАМАЗ		Кояш чыга	ЗӘВӘЛ	ӨЙЛӘ НАМАЗЫ	ИКЕНДЕ НАМАЗЫ	АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР	ЯСТУ НАМАЗЫ
		Сәхәр тәмам	Мәчетләрдә укыла						
01	Чәрш	04:32	05:05	06:35	11:55	12:00	15:19	17:17	18:58
02	Пәнҗ	04:30	05:03	06:33	11:55	12:00	15:21	17:19	19:00
03	Җом	04:27	05:00	06:30	11:55	12:00	15:23	17:21	19:02
04	Шим	04:25	04:58	06:28	11:55	12:00	15:25	17:23	19:04
05	Якш	04:22	04:55	06:25	11:55	12:00	15:27	17:25	19:06
06	Дүш	04:20	04:53	06:23	11:54	12:00	15:28	17:27	19:09
07	Сиш	04:17	04:50	06:20	11:54	12:00	15:30	17:29	19:11
08	Чәрш	04:14	04:47	06:17	11:54	12:00	15:32	17:31	19:13
09	Пәнҗ	04:11	04:45	06:15	11:54	12:00	15:34	17:33	19:15
10	Җом	04:09	04:42	06:12	11:53	12:00	15:36	17:35	19:17
11	Шим	04:06	04:40	06:10	11:53	12:00	15:37	17:38	19:19
12	Якш	04:03	04:37	06:07	11:53	12:00	15:39	17:40	19:21
13	Дүш	04:00	04:35	06:05	11:53	12:00	15:41	17:42	19:24
14	Сиш	03:57	04:32	06:02	11:52	12:00	15:42	17:44	19:26
15	Чәрш	03:55	04:29	05:59	11:52	12:00	15:44	17:46	19:28
16	Пәнҗ	03:52	04:27	05:57	11:52	12:00	15:46	17:48	19:30
17	Җом	03:49	04:24	05:54	11:51	12:00	15:47	17:50	19:33
18	Шим	03:46	04:22	05:52	11:51	12:00	15:49	17:52	19:35
19	Якш	03:43	04:19	05:49	11:51	12:00	15:51	17:54	19:37
20	Дүш	03:40	04:16	05:46	11:51	12:00	15:52	17:56	19:40
21	Сиш	03:37	04:14	05:44	11:50	12:00	15:54	17:58	19:42
22	Чәрш	03:34	04:11	05:41	11:50	12:00	15:56	18:00	19:44
23	Пәнҗ	03:30	04:09	05:39	11:50	12:00	15:57	18:02	19:47
24	Җом	03:27	04:06	05:36	11:49	12:00	15:59	18:04	19:49
25	Шим	03:24	04:03	05:33	11:49	12:00	16:00	18:06	19:51
26	Якш	03:21	04:01	05:31	11:49	12:00	16:02	18:08	19:54
27	Дүш	03:18	03:58	05:28	11:48	12:00	16:03	18:10	19:56
28	Сиш	03:14	03:55	05:25	11:48	12:00	16:05	18:12	19:59
29	Чәрш	03:11	03:53	05:23	11:48	12:00	16:07	18:14	20:01
30	Пәнҗ	03:08	03:50	05:20	11:48	12:00	16:08	18:16	20:04
31	Җом	03:04	03:48	05:18	11:47	12:00	16:10	18:18	20:06